КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 сентябрь г.Казань № 748

2019 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга;

Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнарны муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары арасыннан бер балага 51,9 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 692 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 сентябрь, 748 нче
карары белән расланды

2019 елга Татарстан Республикасы балалары һәм
яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Т/с | Балалар һәм яшьләр ялын оештыру формасы | Норматив чыгымнар, 1 көнгә 1 кешегә койка-урынга сум |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр яны ял лагерындагы смена | 779,05 |
| 2. | Шәһәр яны ял лагерындагы юнәлешле смена | 776,52 |
| 3. | Палатка тибындагы лагерьдагы юнәлешле смена | 921,45 |
| 4. | Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге ял лагерындагы, хезмәт һәм ял лагерендагы смена | 164,30 |
| 5. | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары | 150,25 |
| 6. | Шифаханә-курорт оешмасындагы смена | 1 236,35 |
| 7. | Краснодар крае һәм Крым Республикасы территориясендә социаль актив балалар, предметлар буенча олимпиадаларда, конкурсларда, спорт чараларында приз алучылар, ятим балалар, интернатларда һәм кадет корпусларында тәрбияләнүчеләр лагерындагы юнәлешле смена | 1 105,29 |

___________________________